ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август, 2024 ел № 35/11

Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 403 статьясы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарының (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/7, 2019 елның 7 октябрендәге 33/7, 2019 елның 6 декабрендәге 34/8, 2020 елның 21 февралендәге 37/7, 2021 елның 27 маендагы 7/5, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/7, 2022 елның 28 декабрендәге 29/5 номерлы Карарлары редакциясендә) 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артып киткән административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы бүлмәләргә һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;»;

2) дополнить подпунктом 4.1. следующего содержания:

«4.1) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнүче исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы биналарга һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2025 елда 1,2 процент, 2026 елда 1,5 процент, 2027 елда 1,8 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда 2,0 процент;».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев